СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.04.2024 г. с. Шеланга № 37-210

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставы нигезендә,
Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советына Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Югары Ослан муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетына:

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан, бюджет законнары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге карары проектын эшләү һәм карауга тапшыру.

3. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров